**СОВЕТ ЧЕРНЫШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422710, Республика Татарстан, Высокогорский район, д,Чернышевка, ул. Клубная, 1

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЕРНЫШЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Чернышевка авылы., Клуб ур., 1

Тел./факс 8(84365) 73-5-05, e-mail:Chern .Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**15 июль, 2022 ел** **№ 51**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проектын гамәлдән чыгару хакында**

Федераль һәм региональ законнардагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 124 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы проектын әзерләү максатларында (Советның 07.08.2020 № 139, 18.01.2021 N16 карарлары редакциясендә), әлеге үзгәрешләрне исәпкә алып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7, 20 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чернышевка авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Чернышевка авыл җирлеге Советының 2021 елның 05 октябрь 35 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында» карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Чернышевка авыл җирлеге Советының 2021 елның 05 октябрь 35 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында» карары нигезендә 2021 елның 05 октябрь 11.00.сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Чернышевка авылы., Клуб ур., 1 үткәрелгән гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен гамәлдән чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 207 номерлы карары белән кабул ителгән «««Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл

җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» (Советның 07.08.2020 № 224, 15.01.2021 N18 карарлары редакциясендә) проектын, федераль һәм региональ законнардагы соңгы үзгәрешләрне исәпкә алып эшләргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы О.А.Маланин